**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 30 марты** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Илексаз авыл җирлеге Илексаз торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылы торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 15 ноябрь 2023 елнын 2нче номерлы карарына узгәрешләр кертү турында чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Урамнарның яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Илексаз авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар һәм материаллар сатып алу; агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту));

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Илексаз торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); Илексаз торак пунктының Яшьләр урамындагы вак таш япмасын ремонтлау (вак таш ташу); күрсәткеч такталар һәм юл билгеләре, юлларны буяу өчен буяулар сатып алу Илексаз торак пунктында юл билгеләре кую);

3. Янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын (мотопомпа өчен запас частьләр, сулык өчен материаллар сатып алу; күрсәткеч такта; Илексаз торак пункты янгын сүндерү сулыгы дамбасын киңәйтү өчен туфрак ташу)төзү, ремонтлау);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Илексаз торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); бензокосилка, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу; материаллар, мәгълүмат стенды, ял итү зонасы өчен баннерлар сатып алу);

5. Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (материаллар сатып алу).

2. Әлеге карарны Илексаз авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Ф.М.Гыйлфанов